**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«02» 03 2026 ел Яр Чаллы шәһәре №640

«Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 августындагы 2308 номерлы карарына (2024 елның 25 сентябрендәге 4016 номерлы карар үзгәрешләре белән) үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Башкарма комитетның 2022 елның 14 мартындагы 700 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 августындагы 2308 номерлы карары (2024 елның 25 сентябрендәге 4016 номерлы карар үзгәрешләре белән) белән расланган Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге 1.7 пунктын өстәргә: «муниципаль хезмәт күрсәткәндә, «Бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы, «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.»;

1.2. Регламентның 2.5.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктчаны өстәргә:

«mif/mid форматында атрибутив мәгълүматсыз вектор рәвешендә җир эшләренең чикләре (полигоны) яки җир эшләрен башкару урыны турында мәгълүматлар түбәндәге ысулларның берсе белән:

- МСК 16 системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;
- территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры;
- картографик яки топографик нигездә эш башкару урынының чикләре схемасы.»;

1.3. Регламентның 2.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«mif/mid форматында атрибутив мәгълүматсыз вектор рәвешендә җир эшләренең чикләре (полигоны) яки җир эшләрен башкару урыны турында мәгълүматлар түбәндәге ысулларның берсе белән:

- МСК 16 системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;
- территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры;
- картографик яки топографик нигездә эш башкару урынының чикләре схемасы.»;

1.4. Регламентның 2.5.5 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкару төшерүендә чагылган Татарстан Республикасының гамәлдәге инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына таләпләрне раслау турында» Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 16 сентябрендәге 1308/о номерлы боерыгында бәян ителгән вектор моделе структурасы нигезендә тутырылган семантика белән МСК-16 яки WGS 84 (EPSG:3857) координаталар системасында 1:500 масштабында җир эшләре чикләрендә ясалган, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән дөреслек һәм тулылык предметына килештерелгән инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары.»;

1.5. Регламентның 2.5.6 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкару төшерүендә чагылган Татарстан Республикасының гамәлдәге инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына таләпләрне раслау турында» Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 16 сентябрендәге 1308/о номерлы боерыгында бәян ителгән вектор моделе структурасы нигезендә тутырылган семантика белән МСК-16 яки WGS 84 (EPSG:3857) координаталар системасында 1:500 масштабында җир эшләре чикләрендә ясалган, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән дөреслек һәм тулылык предметына килештерелгән инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары.»;

1.6. Регламентның 2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктчаны өстәргә: «Регламентның 2.6.1-2.6.6 пунктлары нигезендә мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиеш булган документларны тапшырмау яисә каршылыклы белешмәләр булган яки әлеге Регламентның 2.5.6 пункты 2 пунктчасы таләпләренә туры килми торган документлар тапшыру.»;
1.7. Регламентның 3.5.2.1. пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:
«Җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында карар «ТР пространстволы планлаштыру институты» ДБУ белән мәҗбүри килештерелергә тиеш.»;
1.8. 3.3.3.1, 3.4.4., 3.5.2.1, 3.5.2.2 пунктларында «электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә» фразасын «ГИСОГД системасы ярдәмендә» фразасына алыштырырга;
1.9. 3.5.3 пунктында «электрон документ әйләнеше системасында» фразасын «ГИСОГД системасында» фразасына алыштырырга.
2.1. Регламентка 1 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (1 кушымта);
2.2. Регламентка 2 кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (2 кушымта);
2.3. Регламентка 3 кушымтаны яңа редакциядә (3 кушымта) бәян итәргә;
2.4. Регламентка 12 кушымтаны яңа редакциядә (4 кушымта) бәян итәргә;
2.5. 14 кушымтаны (5 кушымта) өстәргә;
2.6. 15 кушымтаны өстәргә (6 кушымта);
2.7. 16 кушымтаны өстәргә (7 кушымта);
2.8. 17 кушымтаны өстәргә (7 кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Җитәкче урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов